КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 30 декабрь г.Казань № 1345

Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм срокларын раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондларының идарә органнарына, җирле үзидарә органнарына, җирле администрация органнарына бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен беркетүгә карата территориаль һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты, җирле бюджет керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2021 елның 16 сентябрендәге 1569 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондларының идарә органнарына, җирле үзидарә органнарына, җирле администрация органнарына бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен беркетүгә карата территориаль һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты, җирле бюджет керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга карата гомуми таләпләрнең 10 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм срокларын расларга.
2. Бу карар, 2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 30 декабрь, 1345 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибе һәм сроклары

1. Бу Тәртип Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондларының идарә органнарына, җирле үзидарә органнарына, җирле администрация органнарына бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен беркетүгә карата территориаль һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты, җирле бюджет керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2021 елның 16 сентябрендәге 1569 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондларының идарә органнарына, җирле үзидарә органнарына, җирле администрация органнарына бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен беркетүгә карата территориаль һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты, җирле бюджет керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга карата гомуми таләпләрнең 10 пункты нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә (алга таба шул ук эзлеклелектә – баш администратор, исемлек) үзгәрешләр кертү механизмын һәм срокларын билгели.

Исемлеккә, шулай ук баш администраторларга беркетелгән Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре классификациясе кодлары составына үзгәрешләр, баш администраторлар составы һәм (яисә) функцияләре үзгәргән, шулай ук Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре классификациясе кодлары структурасын билгеләү һәм бирү принциплары үзгәргән очракларда, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслау турында» 2021 ел, 24 декабрь, 1115 нче карарына үзгәрешләр кертмичә, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы (алга таба – Министрлык) боерыгы нигезендә кертелә.

2. Бюджет классификациясе коды бирелгән исемлеккә, бюджет классификациясе коды исеменә, керем чыганагын администрацияләү өчен нигез булып торган норматив хокукый актлар исемлегенә үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәр баш администраторлары тарафыннан Министрлыкка башкарыла торган вәкаләтләргә үзгәреш кертү өлешендә федераль законнарга һәм алар нигезендә кабул ителә торган Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы законнарына һәм башка норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертелгән көннән 30 календарь көннән дә соңга калмыйча җибәрелә.

3. Тәкъдимнәрне карап тикшерү йомгаклары буенча Министрлык, искәрмәләр булмаган очракта, әлеге тәкъдимнәр кергән көннән 30 календарь көннән дә соңга калмыйча, исемлеккә үзгәрешләр кертү турында Министрлык боерыгын кабул итә, баш тартылган очракта – баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, исемлеккә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында баш администраторга хәбәр итә. Баш администратор, баш тарту сәбәпләрен бетергәннән соң, тәкъдимнәрне кабат җибәрергә хокуклы.

4. Татарстан Республикасы бюджетын оператив үтәү өчен һәм Министрлыкның боерыгы кабул ителгән вакытка кадәр Татарстан Республикасы бюджетына ачыкланмаган керемнәрне минимальләштерү максатларында Министрлыкка Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе адресына, Россия Федерациясе Финанс министрлыгының «Федераль казначылык тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасына керемнәрне исәпкә алу һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары арасында аларны бүлү тәртибен раслау турында» 2020 елның 13 апрелендәге 66н номерлы боерыгы белән расланган Федераль казначылык тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасына керемнәрне исәпкә алу һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары арасында аларны бүлү тәртибенә 8 нче кушымта нигезендә бюджет дәрәҗәләре арасында бүлү нормативларын теркәп, бюджет классификациясенә кертелгән үзгәрешләрне «Читтән торып финанс документлары әйләнеше» гамәли программа тәэминатына кертү өчен (баш администраторның Министрлык адресына мөрәҗәгате нигезендә) мөрәҗәгать итәргә рөхсәт ителә.

______________________________